ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.10.2021 с.Старое Дрожжаное №445

«2020 - 2025 елларга Чүпрәле муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» республика ярдәмче программасына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 25 сентябрендәге 916 номерлы Карары нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 28 апрелендәге 219 номерлы карары белән расланган «2020 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программаның 1 нче кушымтасының «2020 - 2025 елларга Чүпрәле муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләре» 35 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Сатып алына торган торак бина (шул исәптән өлешләп төзү объекты булып тора) яки торак йорт төзелеше Татарстан Республикасы территориясендә булырга яки гамәлгә ашырылырга тиеш.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А. Ф. Җәләловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов